**ГЛАВА АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 Лаишевский район, с. Атабаево
Ул.Молодежная ,д. 1,
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
E-mail Atab.La@tatar.ru

**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

422635 Лаеш районы, Атабай авылы
Яшьлэр урамы , 1нче йорт
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
E-mail Atab.La@tatar.ru

2023 елның 30 октябре 2 номер

КАРАР

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлегенең Атабай торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлегендә Атабай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 9 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка билгеләргә.

1.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Муниципаль район Атабай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга сез ризамы?

- урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм тоту - җирлек юллары эчендә ремонт, юллар сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу, асфальт салу, нигез салу, килешү буенча эшләр өчен түләү (Октябрь урамы буенча Атабай торак пунктында)..

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Атабай авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Советы рәисе : Л.Р.Хәлилова**